ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.12.2025 г.Казань № 695-206/кс-2025

Җылылык белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең) ачык системаларын кулланып, Зәй муниципаль районындагы кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте өчен кайнар суга 2026 ел өчен тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 19.12.2025 ел, №35-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Җылылык белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең) ачык системаларыннан файдаланып Зәй муниципаль районындагы кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга «Татэнерго» акционерлык җәмгыятеннән (алга таба – «Татэнерго» АҖ) бирелә торган кайнар суга, шушы карар кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Татэнерго» АҖ иреклe файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү

һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В. Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
19.12.2025 № 695-206/кс-2025
карарына кушымта

# Җылылык белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең) ачык системаларыннан файдаланып Зәй муниципаль районындагы кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга «Татэнерго» АҖ бирелә торган кайнар суга 2026 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы | Ел | Җылылык чыганагы компоненты, сум/куб.м. | Җылылык энергиясе компоненты | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Бер ставкалы, сум/Гкал | Ике ставкалы | |
| | | | | | Егәрлек өчен ставка, аена мең сум/1 Гкал/сәг | Җылылык энергиясе өчен ставка, сум/Гкал |
| | Зәй муниципаль районы (Зәй шәһәре кулланучылары өчен) | | | | | |
| 1 | «Татэнерго» АҖ* | | | | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)** | 01.01.2026 башлап 30.09.2026 кадәр | 37,34 | 3262,22 | - | - |
| | | 01.10.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 42,46 | 3709,14 | - | - |
| 1.2 | Бүтән кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 01.01.2026 башлап 30.09.2026 кадәр | 30,61 | 2673,95 | - | - |
| | | 01.10.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 34,80 | 3040,28 | - | - |

* «Татэнерго» АҖ өчен җылылык чыганагына җылылык чыганагы компонентылары исәпләмәсендә кабул ителә торган тарифлар Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2024-2028 елларга «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан Зәй шәһәрендәге кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җибәрелә торган җылылык чыганагына тарифлар билгеләү турында» 15.12.2023 №738-94/тэ-2023 карары белән билгеләнгән. ** Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында бирелә.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге